РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ**
**Малосалтыковского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Б. Урманче, 9 с. Малые Салтыки, 422812
тел. (8277)36-2-18, факс: (8277) 36-2-18
ОКПО 04308953 ОГРН 2061672001378000911
ИНН/КПП 1622001675/1162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Кече Салтык**
**авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

Б.Урманче урамы, 9,Кече Салтык авылы, 422812,
тел. (8277)36-2-18, факс: (8277) 36-2-18
ОКПО 04308953 ОГРН 2061672001378000911
ИНН/КПП 1622001675/1162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**10 ноябрь 2020 ел** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Яшелчә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2019 елның 02 декабрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Яшелчә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Яшелчә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Яшелчә авылы зираты коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);

- Яшелчә авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү килешү буенча).

« ЭЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче урамы, 9;

-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Гагарин урамы, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 (ун) көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы А.Г. Җиһаншин**